КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 4 декабрь г.Казань № 1039

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2016 ел, 18 июнь, 414 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 834 нче; 2018 ел, 30 июль, 618 нче; 2020 ел, 18 май, 402 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1181 нче; 2023 ел, 6 март, 215 нче; 2023 ел, 9 июнь, 706 нчы; 2024 ел, 30 октябрь, 937 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пункт таблицасының 15 пункты үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктның өченче абзацында «, шулай ук социаль хезмәттән файдалану өчен медицина ягыннан каршылыклар булу (булмау) турында таныклый торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

13 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин